| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ФЕДОРОВСКИЙ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.03.2023 ел. № 64

Федоровский ав.

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 39 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 39 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1. пунктны түбәндәге эчтәлекле 2.1.3 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.1.3 Россия Федерациясендә (алга таба - хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзалары турында Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) хәрби хезмәткәр белән никахта торучы (торучы) ир яисә хатын;

2) 18 яшькә җитмәгән яисә бу яшьтән өлкәнрәк хәрби хезмәткәрләрнең балалары, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид булган булсалар, шулай ук көндезге бүлектә белем бирү оешмаларында белем алучы балалар - уку тәмамланганчыга кадәр, әмма алар 23 яшькә җиткәннән дә соңга калмыйча.»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның 1.1 пунктындагы 1.1 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы физик затлар мөлкәтенә салымны 2021-2022 еллардагы салым чорлары өчен исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 39 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советының 2022 елның 30 ноябрендәге 54 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге стендларында бастырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Федоровский авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе — Ф.Ф.Зәйнуллин